Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
"Муслюмовская гимназия"
Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан

Рассмотрено
Руководитель ШМО
_______________
Авзалова З.З.
Протокол №1 от 28.08.2023

Согласовано
Укыту эшләре буенча директор урынбасары:
_______________
Миннегалиева Л.Р.

Утверждено
Директор гимназии
_______________
Мирзаянов А.Ф
Приказ № 153 от 31.08.2023

**Программа внеурочной деятельности по родному(татарскому)языку**
**"ЭЗЛӘНҮ ЮЛЫНДА"**
**для 8 классов**

Дәрестән тыш эшчәнлек курсының планлаштырыла торган нәтиҗәләре:

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр**:

- укучының җаваплылык хисен активлаштыру;
- укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәт булдыру;
- баланың үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен төшендерү;
- төрле чыганаклардан (сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслар һ.б.) танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек мәгълүматлар табарга күнектерү.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру буенча планлаштырыла торган нәтиҗәләр:**

**Танып-белү гамәлләре:**

- әдәби әсәрне дөрес аңлап уку һәм анализлау;
- дөрес нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерү;
- сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булдыру;
- үз фикереңне исбатлый һәм яклый алырга күнектерү;
- әсәр хакында дөрес фикер йөртә алу.

**Коммуникатив гамәлләр:**

- иптәшеңне тыңлый, ишетә белү, ишеткәнен үз фикере белән чагыштыру;

- нәтиҗәгә килгәнче, төрле карашларны өйрәнү һәм дөрес юлны сайлау;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада башкаларга җиткерә белү;
- килеп чыккан проблемаларны уртага салып хәл итү;
- төркемнәргә берләшү, бер фикергә килә белү;
- өлкәннәр һәм яшьтәшләрең белән продуктив уртак гамәл оештыру;
- текст буенча сораулар бирә белү.

**Регулятив гамәлләр:**

- өстәмә уку һәм үзлегеңнән белем алуны планлаштыра белү;
- аларны башкару чараларын белү һәм анализлау;
- план буенча эшли белү;
- үз фикерләреңне мөстәкыйль дәлилләү;
- үзанализ һәм үзбәя булдыру.

**метапредмет нәтиҗәләр**:

- язу һәм сөйләм осталыгын үстерү, мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, материалны төркемли, үз фикерен дәлилли, кирәк икән – үзгәртә-төгәлләштерә, нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белергә, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алырга һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләргә күнектерү;
- баланың үз эшчәнлеген һәм әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белүенә, мөстәкыйль карарлар кабул
- итә һәм аларны җиренә җиткереп үти алуына ирешү;
- төрле чыганаклар белән эшләргә, аларны табарга, мөстәкыйль рәвештә кулланырга, төркемләргә, чагыштырырга, анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.

**предмет нәтиҗәләре**:

- фикер алышуда катнашырга, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларын расларга һәм дәлилләргә, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.
- милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә өйрәтү;
- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүенә ирешү;
- автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсен формалаштыру.
- әдәби әсәрнең образлы табигате хакында гомуми мәгълүматый күзаллау булдыру, аның эстетик кыйммәтен тою хисе тәрбияләү;
- баланың әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта әдәби һәм тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белүенә ирешү;
- рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә, геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү.

**предметара нәтиҗәләр:**

укучыларда әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре ярдәмендә мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият–сәнгать белән даими кызыксыну формалаштыру;

- татар теленә бәйләнештә, туган телнең матурлыгына һәм байлыгына хөрмәт тәрбияләү;
- мәдәниятара бәйләнешләрне саклау, укучының башка милләтләр мәдәнияте һәм әдәбиятыннан мәгълүматлы, башка халыкларның сүз сәнгатенә хөрмәтле мөнәсәбәттә, толерант булуына ирешү.

Программаның эчтәлеге:

| № | Тема | Эчтәлек | Сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Проект эшчәнлеге. | Проектлар эшләргә өйрәнү. Проект эшендә ахырдан килеп чыгачак продукт турында күзаллау булдыру. Проектны тормышка ашыру буенча эшне оештыру | 4 |
| 2 | Фәнни-тикшеренү эшчәнлеге. | Проблемага караган теорияне өйрәнү, методика сайлау, материал туплау, анализ ясау, нәтиҗәләр чыгару. | 10 |
| 3 | Олимпиадага әзерләнү. | Төрле авырлыктагы биремнәр эшләү. | 5 |
| 4 | Сөйләм культурасы | Сөйләм этикасын өйрәнү | 7 |
| 5 | Атналыкка әзерләнү | Муса Җәлил, Габдулла Тукай туган көннәренә квест уен әзерләү | 2 |
| 6 | Китапханәгә бару. | Китапханәдә язучылар турында өстәмә мәгълүмат табарга өйрәнү. | 1 |
| 7 | Китап укучылар конференциясе үткәрү | Язучы иҗатын өйрәнү һәм башкаларга да тәкъдим итү | 1 |
| 8 | Музейга бару | Музейдагы экспонатларны өйрәнү | 5 |

Дәрестән тыш эшчәнлекнең календарь-тематик планы

| № | Бүлекләр исеме | Тема | Сәгать саны | Үткәрү формасы | Укучыларның эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Проект эшләргә өйрәнү. | Нәрсә ул проект? | 1 | Тренинг | Проектның ахырдан килеп чыгачак продукт турында күзаллау. (рәсем, презентация, китапнамә ) |
| | Яраткан язучым проекты | Яраткан язучым | 1 | Китапханәгә экскурсия | Күзәтү, сораулар бирү, әңгәмәдә катнашу |
| 2 | Проект эше | Тема!? Син кайда? | 1 | Тренинг | Тема эзләү, исем кую |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | темалары | | | | |
| 3 | Проект яклап чыгыш ясау | Чыгыш ясаганда үзеңне ничек тотарга? | 1 | Мастер - класс | Чыгыш әзерләү, чыгыш ясау |
| 4 | Якташ язучылар иҗатыннан яраткан әсәрем проекты. | Минем яраткан китабым | 1 | Конференция | Презентация әзерләү , китапнамә төзү, китапны укып тәкъдир итү |
| 5 | Фәнни-тикшеренү эшчәнлеге. | Фәнни-тикшеренү эшен ничек эшләргә? | 1 | Тренинг | Иҗади эш:интернет материалларын өйрәнү, анализ ясау, фәнни эшнең асылына төшенү |
| 6 | Текст белән эш. | Образлы сурәтләү чаралары. | 1 | Әңгәмә. Доклад яклау. Диспут. Түгәрәк өстәл. | Аңлатмалы сүзлек һәм башка чыганаклар белән эш<br>Әдәби текстлар язып карау |
| 7 | Текст белән эш. | - Эпитет һәм чагыштырулар.<br>- Синонимнар. Антонимнарның образлы сөйләмдәге роле.<br>- Омонимнар, аларның төрләре (омографлар, омофоннар, омоформалар). | 1 | Викторина. Әңгәмә. Түгәрәк өстәл. | Тезмә һәм чәчмә әсәрләрне анализлау |
| 8 | Текст белән эш. | Дөньяны танып-белүдә образлы фикер йөртү | 1 | Әңгәмә. Түгәрәк өстәл. | Әдәби әсәрдән үзеңнең текстыңны тәкъдим итү. |
| 9 | Троплар – матур сөйләмнең алтын бизәкләре: | Метафора, метонимия, синекдоха.<br>-Аллегорияләр. Эзоп теленең үзенчәлекләре. | 1 | Дебатлар. | Дебат үткәрү. Һәр команда үзенең фикерен яклый, каршы якны кире кага. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | - Ирония һәм парадокс, аларның үзенчәлекләре. | | | |
| 10 | Р. Фәхреддин мирасы белән танышу | Гыйбрәтле сүзләр | 1 | Риза Фәхретдин музеена экскурсия. | Р. Фәхреддин мирасын өйрәнү. |
| 11 | Шул вакытта шулай диясе калган! | Уйнап сөйләсәң дә, уйлап сөйлә. | 1 | Интеллектуаль ярыш | Интернеттан , газетадан төрле кызыклы материаллар табу, фикер алышу, тормыштан ситуацияләр сәхнәләштерү. |
| 12 | Т.Миңнуллин “Утырып уйлар уйладым” (публицистик язмалар китабына күзәтү, язмаларын уку). | Журналист эзләнүе | 1 | Газетага мәкалә язу | Иҗади эш эшләү. |
| 13 | Ник Вуйчичның 20 көчле цитатасы | Сине үз гамәлләрең шатландырсын һәм илһамландырсын. | 1 | Шагыйрь Мөҗәһит Әхмәтҗанов белән очрашу. | Очрашу, күзәтү, сораулар әзерләү, иҗат итү. |
| 14 | Фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең бер төре буларак шәҗәрә тәзү | Безнең тамырлар | 1 | Мастер - класс | Шәҗәрә төзү |
| 15-19 | Олимпиадага әзерләнү. | Олимпиадага әзерләнәм | 5 | Тренинг<br>Кейс<br>Түгәрәк өстәл | Биремнәр эшләү |
| 20- | Сөйләмдә сүзнең | Матур сөйли белү дә бер | 2 | Квест | Татар теле атналыкларында укучылар |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 22 | тоткан урыны һәм көче | сәнгать | | | алдында чыгыш |
| 23 | Сөйләм культурасына өйрәнәбез | Сөйләм тәртибе этикасы | 1 | квест | |
| 24 | Сөйләм культурасы | Башка кеше сөйләмен кабул итү һәм бәяләү. | 1 | Язучылар белән очрашу | Тыңлау, сораулар бирү |
| 25 | Сөйләм культурасы | -Аудиториядә (кешеләр каршында) чыгыш ясау (күрү контакты, тавыш контакты). | 1 | Тренинг | Чыгыш ясау |
| 26 | Әңгәмә кору һәм бәхәсләшү нигезләре. | Бәхәсләшә беләсеңме? | 1 | Түгәрәк өстәл | Төрле ситуацияларга диалоглар төзү |
| 27-28 | Атналыкка әзерләнү | Муса Җәлил, Габдулла Тукай туган көннәре | 1 | Квест уен | 5-6 нчы сыйныф укучылары белән бәйрәм әзерләү; биремнәр, шигырьләр, җырлар өйрәтү |
| 29 | Китапханәгә бару. | Күренекле шәхесләр белән очрашу | 1 | Экскурсия | Сораулар әзерләү, очрашу, аралашу |
| 30 | Китап укучылар конференциясе | Минем яраткан әсәрем | 1 | Конференция | Бирелгән әдәби әсәрне уку, биремнәр әзерләү, чыгыш ясау |
| 31-35 | Музейга, авылымның истәлекле урыннарына экскурсия | Авылың тарихын беләсеңме? | 1 | Экскурсия | Күзәтү, әңгәмә |